ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль, 2019 ел № 30/8

Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 санлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 санлы Карары белән (Шәһәр Советының 2014 елның 23 декабрендәге 36/7, 2015 елның 23 июлендәге 41/7 санлы Карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 2.1, 2.2 пунктчалары белән тулыландырырга:

«2.1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә әлеге Нигезнамәдә каралмаган реклама конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми.

2.2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштырганда һәм эксплуатацияләгәндә оештыру-хокукый формасына һәм ведомствога карамыйча, барлык физик һәм юридик затлар, шулай ук шәхси эшмәкәрләр өчен әлеге Нигезнамә таләпләрен үтәү мәҗбүри.»;

2) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Реклама конструкцияләре һәм аларның территориаль урнаштырылуы:

– техник регламент таләпләренә җавап бирергә тиеш. Техник регламентлар булмаган очракта, «Автомобиль юлларында, шәһәр һәм авыл җирлекләре территориясендә тышкы реклама.Тышкы реклама чараларына гомуми таләпләр. Урнаштыру кагыйдәләре» турында ГОСТ Р 52044-2003 таләпләре кулланыла;

– әлеге Нигезнамә белән билгеләнгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзелешнең тышкы архитектурасы таләпләрен исәпкә алып башкарылырга тиеш;

– реклама конструкцияләре урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт кәгазе нигезендә урнашытырылырга һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәрендә каралган халәттә булырга тиеш;

– электр белән тәэмин итү системасыннан авария хәлендәге өзеп тору системасы куелырга һәм, электрга тоташтырылган очракта, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килергә тиеш.»;

3) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Реклама конструкциясе хуҗасы:

1) реклама конструкциясен монтажлау (демонтажлау) эшләрен тәмамлаганнан соң территорияне төзекләндерергә һәм бинаның тышкы кыяфәтен тәртипкә китерергә тиеш. Фундамент блогына урнаштырылган реклама конструкциясе фундамент блогы белән бергә сүтелергә тиеш;

2) реклама конструкциясе проектын эшләргә һәм реклама конструкциясен урнаштыруга, эксплуатацияләүгә рөхсәт алырга тиеш;

3) үз вакытында ремонт ясарга, реклама конструкциясе урнаштырылган урынны җыештырырга тиеш;

4) бина, корылмаларны ремонтлау, реконструкцияләү яки тәртипкә китерү вакытына реклама конструкциясен вакытлыча демонтажларга тиеш;

5) бина, корылмаларның төсен, тышлыгын һәм башка конструктив эшләнмәләрен үзгәрткәндә, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә яңа рөхсәт алырга тиеш.»;

4) 20 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«20. Яр Чаллы шәһәре территориясендәге түбәндәге төрдәге реклама конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителә:

1) аерым торучы реклама конструкцияләре;

2) бина һәм корылмаларда урнаштырылучы реклама конструкцияләре.

Реклама конструкцияләренә таләпләр һәм аларны Яр Чаллы шәһәре территориясендәге бина һәм корылмалар фасадларында урнаштыру вариантлары Башкарма комитет карары белән раслана.»;

5) 21, 22 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Аерым торучы реклама конструкцияләре түбәндәге типларга бүленә:

1) суперсайт һәм суперборд – тышкы яки эчке яктырту белән эшләнгән зур форматтагы аерым торучы щитлы типлаштырылган реклама конструкцияләре

Суперсайт һәм суперборд фундамент, таяныч, каркас һәм мәгълүмат мәйданыннан тора. Суперсайтның мәгълүмат мәйданының үлчәме 5,0 х 15,0 м, супербордның – 4,0 х 12,0 м була.

Суперсайт һәм суперборд якларының саны өчтән дә артык булмаска тиеш.

Сурәтләрне автомат рәвештә алыштыру очрагында мәгълүмат мәйданы экспозиция өслеге мәйданыннан чыгып билгеләнә.

Суперсайт һәм суперборд фундаменты җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

2) күп модульле конструкция – тышкы яки эчке яктыртулы зур форматтагы аерым торучы щитлы типлаштырылган реклама конструкциясе. Күп модульле конструкция фундамент, нейтраль төстәге (соры, аксыл көрән, графит, кара, көрән) материал белән тышланган каркас, 3,0 х 6,0 м үлчәмле мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

3) еврощит – тышкы яки эчке яктыртулы урта форматтагы аерым торучы щитлы типлаштырылган реклама конструкциясе.

Еврощит фундамент, таяныч, каркас һәм 3,0 х 6,0 м үлчәмле мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

Еврощит кырларының саны өчтән дә артык булмаска тиеш.

Сурәтләрне автомат рәвештә алыштыру очрагында мәгълүмат мәйданы экспозиция өслеге мәйданыннан чыгып билгеләнә.

Еврощит фундаменты җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

Еврощит каркасының аскы ягы җир өслегеннән 4,5 метрдан да ким булмаган биеклектә урнашырга тиеш.

Бер яклы вариантта эшләнгән еврощитның икенче ягы декоратив күренешле булырга тиеш.

4) пилларс – эчке яктырту белән эшләнгән кече форматтагы аерым торучы типлаштырылган реклама конструкциясе.

Пилларс фундамент, каркас һәм 1,4 х 3,0 м. үлчәмле мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

Пилларс якларының саны өчтән дә артык булмаска тиеш.

Пилларс фундаменты җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

Пилларсның мәгълүмат кыры үтә күренмәле поликарбонат яки пыяла белән сакланган булырга тиеш.

5) пилон – эчке яктыртулы кече форматтагы аерым торучы типлаштырылган реклама конструкциясе.

Пилон фундамент, каркас һәм 1,2 х 1,8 м. үлчәмле мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

Пилон яклары саны икедән дә артык булмаска тиеш.

Сурәтләрне автомат рәвештә алыштыру очрагында мәгълүмат кырының мәйданы экспозиция өслеге мәйданыннан чыгып билгеләнә.

Пилонның мәгълүмат мәйданы пыяла белән сакланган булырга тиеш.

Пилон фундаменты җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

6) афиша конструкциясе – индивидуаль, аерым торучы щитлы, кече форматлы реклама конструкциясе.

Афиша конструкциясе фундамент, каркас, рам конструкциясе һәм мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

Афиша конструкциясе фәкать театр репертуарлары, кинотеатрлар, спорт һәм башка массакүләм чаралар, иҗтимагый, мәдәни-күңел ачу, спорт-сәламәтләндерү характерындагы вакыйгалар турында реклама урнаштыру өчен каралган.

7) медиа экран – аерым торучы, сурәт һәм видео тапшыручы реклама конструкциясе. Медиа экран фундамент, таяныч, каркас һәм мәгълүмәт (яктылык диодлы) өслегеннәнән гыйбәрәт.

Яктылык диодлы модульләрнең рөхсәт ителгән яктылык билгеләнеше:

– тәүлекнең якты вакытында – 6370 кд/кв. м.

– тәүлекнең караңгы вакытында – 851 кд/кв. м.

Медиа экран яклары саны өчтән артык булмаска тиеш. Бер яклы медиа экран урнаштырган очракта, аның икенче ягы декоратив күренешле булырга тиеш.

Медиа экран фундаменты җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

8) стела – аерым торучы, киң күләмле, индивидуль эшләнгән, кече (биеклеге 6,0 м дан артмаска тиеш) яки зур (6,0 м дан артык) форматтагы типлаштырылган реклама конструкциясе, фундамент, нейтраль төстәге (соры, аксыл көрән, графит, кара, көрән) материал белән тышланган каркас һәм эчке яктан яктыртулы мәгълүмат мәйданыннан гыйбәрәт.

Стела яклары саны өчтән артык булмаска тиеш.

Фундамент җир өстеннән калкып тормаска тиеш.

Сурәтләрне автомат рәвештә алыштыру очрагында мәгълүмат кырының мәйданы экспозиция өслеге мәйданыннан чыгып билгеләнә.

Стела бер яклы вариантта эшләнгән очракта, аның икенче ягы декоратив күренешле булырга тиеш.

9) флаг композициясе – нигездән, бер яки берничә флагштоктан (әмма өч флагштоктан да артык түгел) һәм мәгълүмат мәйданын хасил иткән тукымадан торган аерым реклама конструкциясе.

Флаг композицияләрен урнаштыру тыела:

– милекче, кулланучы милкендә булып, шәхси эшмәкәрнең, оешманың урнашкан урыны һәм бинасы урнашкан җир участогыннан читтә, шулай ук файдалану, машина кую урыннары булдыру максатында бирелгән җир участокларыннан читтә;

– фундамент уентыгын декоратив итеп эшләү өчен техник мөмкинлекләр булмаганда.

22. Биналарда һәм корылмаларда реклама конструкцияләрен урнаштыру урыннары объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе белән билгеләнә.

Биналарда, корылмаларда яктыртуның ачык ысулын кулланып

конструкцияләр урнаштыру рөхсәт ителми.

Биналарда һәм корылмаларда түбәндәге типтагы конструкцияләр урнаштырыла:

1) түбә җайланмасы– бина түбәсендә урнаштырылган фонсыз, эчке яктан яктыртулы, аерым торучы символлар (хәрефләр, саннар, логотиплар, билгеләр, сәнгать элементлары) күренешендәге мәгълүматлы индивидуаль реклама конструкциясе.

Түбә җайланмасы имиджлы реклама конструкциясе булып тора һәм Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерелгән реклама корылмаларын һәм объектта тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе нигезендә оешманың торган урынына бәйләнешсез урнаштырыла.

Түбә җайланмасының мәгълүмат мәйданы әлеге түбә җайланмасын урнаштыру тәгаенләнгән турыпочмаклык мәйданыннан чыгып хисаплана.

Түбә конструкцияләрен түбәндәге биеклектә урнаштыру рөхсәт ителми:

– бер катлы биналар, стационар булмаган сәүдә объектлары өчен – 0,5 м дан артык;

– ике катлы биналар, стационар булмаган сәүдә объектлары өчен – 1,0 м дан артык;

– өч - биш катлы биналар өчен –1,5 м дан артык;

– алты -тугыз катлы биналар өчен – 2,0 м дан артык;

– 10-15 катлы биналар, 16 катлы һәм аннан да биегрәк биналар өчен – 2,5 м дан артык;

түбә конструкцияләрен түбәндәге озынлыкта урнаштыру рөхсәт ителми:

– конструкция урнаштырылган фасад (фасад өлеше) озынлыгының 1/2 өлешеннән дә озынрак итеп.

Әгәр түбә җайланмасында аерым график элемент (хезмәт күрсәтү билгесе, логотип) булган очракта, аның биеклеге хәрефләр биеклегеннән артып китәргә мөмкин, ләкин 3/1 өлештән артык түгел.

Түбә җайланмасының ныгыту элементларының кырлары һәм өске ягы әлеге конструкция периметрыннан чыгып торырга тиеш түгел. Түбәдән (парапеттан) түбә җайланмасы мәгълүмат мәйданының аскы кырыена кадәр ара 1 метрдан артырга тиеш түгел.

Түбә җайланмасында мәгълүматны алыштыру шәһәр Башкарма комитетының вәкаләтле органнары белән өстәмә килешүне таләп итә.

Объектны проектлау, төзү, сафка бастыру барышында каралган һәм объектны, корылманы эксплутацияләгәндә алыштыруны күздә тотмаган түбә җайланмасы реклама конструкциясе булып саналмый;

2) фон конструкциясе – реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе нигезендә диварларның тышкы өслегендә, биналарның фронтонында, стационар булмаган сәүдә обьектларыныуң керү өлешендә, тәрәзәләрдә (витриналарда) түбәндәгечә урнаштырылучы индивидуаль реклама конструкциясе:

– каркас һәм ныгыту элементларыннан торган зур күләмле яктыртылучы хәрефләр, декоратив элементлар һәм билгеләр рәвешендә;

– зур өстәмә элементлары булган ябык киселешле, инкрустацияле, яктыртылучы тартма рәвешендә.

Фон конструкцияләрен урнаштыру тыела:

– стационар булмаган сәүдә объекты, бинаның тәрәзәләре арасындагы дивар биеклегенең 2/3 өлешеннән артык биеклектә;

– фриз биеклегенең (шул исәптән янкормаларынң) 2/3 олешен алып торган текст формасындагы мәгълүматны;

– козырёкта 0,5 м дан артык биеклектә

– 15 м дан артык озынлыкта һәм фасад озынлыгының 70% нан артык итеп, фон конструкциясенең өске ягы чиктәш фасадның өске тәрәзәләреннән өстәрәк булырга тиеш түгел;

– беренче кат уеымнарында урнаштырганда - уемның биеклегеннән 0,5 м дан, озынлыгыннан 50 % тан артык итеп;

– подвал, цоколь, беренче катның тышкы диварында урнаштырганда, фон конструкциясенең аскы өлеше һәм җир арасын 0,6 м дан кимрәк калдырып;

– күп катлы йортларның икенче катыннан өстәрәк (күп картлы йортның торак булмаган янкормаларыннан тыш);

– бина фасадлары диварлары өслегенә турыдан-туры төшерелгән сурәт белән;

– әлеге бинада гамәлдә булу срогы тәмамланмаган рөхсәт (килешү) нигезендә билгеләнгән түбә конструкциясе булган очракт фронтонда, өске катның фризасында урнаштыру;

– бина фасадында суперграфика белән .

Суперграфика – фасадларны архитектура-сәнгати бизәү алымнарының визуаль үзләштерүне кочәйтә торган бер төре (рәсем, бизәк, барельеф, мозаика).

Коймада урнаштырылган фон конструкциясе вакытлы реклама конструкциясе булып санала.

Коймада урнаштырылган фон конструкциясе койма секциясенең өске ягына тигезләп куелырга тиеш. Мондый конструкция мәйданы койма секциясе мәйданының 75 процентыннан артмаска тиеш;

3) консоль конструкциясе – бина фасады яссылыгына турыпочмак ясап, стационар булмаган сәүдә объектына локальләштереп, диварның тышкы өслегенең почмаклы урыннарында урнаштырылучы индивидуаль реклама конструкциясе.

Түбәндәге консоль конструкцияләрен урнаштыру тыела:

– озынлыгы һәм биеклеге 1,0 м дан артык булса;

– фасад өслегеннән 0,2 м дан ераграк итеп урнаштыру;

– фасад кырыннан 0,2 м дан ераграк һәм конструкциянең аскы өлеше белән җир арасын 2,5 м дан кимрәк итеп;

– бинага керү ишекләре өстендә.

4) витрина конструкциясе – бинага, стационар булмаган сәүдә объекты витринасы, тәрәзә пыялаларының эчке ягына фон конструкциясе рәвешендә куелучы индивидуаль реклама

конструкциясе, ул каркас, кырлары декоратив ысул белән эшләнгән мәгълүмат мәйданы, тәрәзә уемы мәйданының өлешен алып торган асылма элекментлардан (биеклеге һәм озынлыгы буенча витринаның пыяла өслеге үлчәменең яртысы кадәр) гыйбәрәт.

Витрина конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми:

– мәйданы 2,0 кв. м. дан ким булган тәрәзә уемында;

– бина ягыннан витрина пыялас һәм витрина конструкциясенә кадәр ара 0,15м дан ким булганда;

– витрина пыяласы өслеген буяу һәм декоратив пленка белән каплау юлы белән эшләгәндә;

– витрина өслеген пыялалау урынына яктыртылучы тартмалар белән алыштырганда.

5) фасад медиа экраны – бина һәм корылма фасадларына урнаштырылучы, яктылык диодлары ярдәмендә сурәт һәм видео тапшыручы, билгеләнгән сандагы яктылык модульләре белән эшләнгән индивидуаль реклама конструкциясе.

Яктылык модульләренең рөхсәт ителгән билгеләнеше:

– тәүлекнең якты вакытында – 6370 кд/кв.м.

– тәүлекнең караңгы вакытында – 851 кд/кв.м.

Медиа экранның бина фасадында урнашу урыны һәм аның зурлыгы бинаның зурлыгыннан һәм архитектура үзенчәлегеннән чыгып билгеләнә. Видеоэкран үлчәме ул урнашкан фасад үлчәменнән зуррак булмаска тиеш.»;

6) медиа фасад – мәгълүмат мәйданы 50 кв.м. дан ким булмаган, бина, корылма яисә дивар пластикасын кабатлаучы металл каркаста урнаштырылучы һәм электрон – цифрлы сурәтне (текст формасындагы мәълүматны, графика, анимация, видеоны) тапшыручы, билгеләнгән сандагы яктылык модульләре белән эшләнгән индивидуаль яктылык үткәрүче реклама конструкциясе.

Яктылык модульләренең рөхсәт ителгән билгеләнеше:

– тәүлекнең якты вакытында – 6370 кд/кв.м.

– тәүлекнең караңгы вакытында – 851 кд/кв.м.

Медиа фасад зурлыгы бинаның зурлыгыннан һәм архитектура үзенчәлегеннән чыгып билгеләнә. Торак йорттагы медиа фасад, визуаль күренеш үзенчәлекләрен һәм бинаның архитектура үзенчәлекләрен исәпкә алып, бина фасадының максималь мәйданын биләргә тиеш. »;

6) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү аларны урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт кәгазе нигезендә рөхсәт ителә. Рөхсәт алу өчен таләпләр күчмә сәүдә пунктларына, урам зонтикларына, күрсәтелгән объектларда реклама урнаштырган очракта (реклама урнаштыру өчен билгеләнгән конструкцияләрне һәм җайланмаларны кулланмыйча гына урнаштырганда), кагылмый.»;

7) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып язмача яки электрон документ рәвешендә рөхсәт бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүчегә, аннан кирәкле документларны кабул иткән көннән алып, ике ай эчендә җибәрелергә тиеш.»;

8) 41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«41. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалануга килешү биш елга төзелә. Искәрмәләр:

– 12 айдан да артмаган вакытка вакытлы реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр;

– Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге яйсә дәүләт милкендәге күчемсез милектә, бинада, җир участогында суперсайт, аерым торучы яки фасадтагы медиаэкран, медиа фасад урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр 10 елга төзелә.

Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү турында килешү вакыты тәгәлләнгәч, якларның килешү буенча йокләмәләре дә гамәлдән чыга. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү «Реклама турында» Федераль закон һәм гражданлык законнары нормаларында каралган тәртиптә төзелә.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев